ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ  АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫЗЫЛТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

2024 ел, 19 февраль № 115

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Кызылтау авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Кызылтау авыл җирлеге советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлеге Советының 2019 елның 8 ноябрендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Кызылтау авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12.2 пунктча өстәргә:

«12.2) «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән мәгълүмат системасында финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы  федераль бюджет акчалары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) булган  капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр төзи;».

2.Әлеге карарны а Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм җирлекнең мәгълүмат стендлары аша халыкка җиткерергә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлек башлыгына йөкләргә.

Кызылтау авыл җирлеге Башлыгы,
Кызылтау авыл җирлеге Советы рәисе М.Г.Нуриев